ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлегенең Андреевка авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2023 елның 23 октябре. № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлегенең Андреевка авылында гражданнар җыены

КАРАР:

1.2024 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлегенең Андреевка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт үтүче Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрбиләреннән, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

-халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү.

3."Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында "бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/, «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында:http://novosheshminsk.tatar.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Андреевка авылы, Үзәк урамы, 5 нче йорт янындагы мәгълүмат стендында кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә игълан итәргә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Петропавел авыл җирлеге башлыгы
Яңа Чишмә муниципаль районы Д.С.Никитин

СОВЕТ ПЕТРОПАВЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ